РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ЕВЛАШТАУСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
3, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Евлаштау, ул. Ш.Бариева, д.23
тел. (84362) 46-8-49

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЯВЛАШТАУ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Явлаштау авылы, Ш.Бариев урамы, 23
йорт
тел. (84362) 46-8-49

e-mail: Evlash.Sab@tatar.ru

23 сентябрь 2019 ел № 22

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Явлаштау авыл җирлеге Советының
14.01.2012 елгы №2 карары белән расланган
“Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Явлаштау авыл җирлеге мәнфәгатьләрендә
ачык сервитутларны билгеләү һәм туктату тәртибенә”
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 26.02.2019 елгы №127 “Татарстан Республикасы мәнфәгатләрендә ачык сервитутларны билгеләү һәм туктату тәртибенә үзгәрешләр кертү турында” карарына туры китереп, Явлаштау авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге мәнфәгатьләрендә ачык сервитутларны билгеләү һәм туктату тәртибен раслау турында” 12.01.2012 елгы №3 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге мәнфәгатьләрендә ачык сервитутларны билгеләү һәм туктату тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны “Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге белән каралган очраклардан тыш” сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. 3 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

“3. Ачык сервитут:

1) җир участогы аша үтү яки бару, шул исәптән гражданнарның гомуми кулланылыштагы су объектлары яки аның яр буе полосаларына иркле керүе максатында;

2) җир участогына межалау билгеләрен, дәүләт геодезик челтәрләренең геодезик пунктларын, гравиметрик пунктлар, нивелир пунктлар һәм аларга якын килү юлларын урнаштыру;

3) җир участогында дренаж эшләре уздыру;

4) су объектларыннан су ресурсларын алганда;

5) җир участогы аша авыл хуҗалыгы хайваннарын куып алып чыкканда;

6) җир участогында билгеләнгән шартларда җирле шартларга һәм гореф-гадәтләргә срогы туры килгәндә, печән чабу, авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү;

7) җир кишәрлеген ау һәм балык тоту, аквакультура( балык үрчетү) максатларында кулланган очракларда билгеләнә".

1.3. 15 пунктның беренче абзацында "җир участогының кадастр паспортына" сүзләрен "күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына" сүзләре белән алыштырырга;

1.4. 16 пунктның өченче абзацында "күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрына" сүзләрен "күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына" сүзләренә алыштырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ evlashtay адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырырга.

9. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

10. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Явлаштау авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Нуриев